СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 с. Куралово 5-33

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне юкка чыгару хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019нчы елның 16нчы декабреннән 432-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Советының 2017нче елның 27нче сентябрендәге 27-119нчы номерлы карары белән расланган бердәм башкарма орган сыйфатында яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы В. А. Квашнева